**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 30 апрелендәге 1345 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 1 апрелендәге 940 номерлы**
**«“Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының**
**Мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесе составындагы**
**муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләренең**
**һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм**
**мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзләренә тапшырылган**
**дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган мәгълүмати-методик бүлекләр**
**хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне**
**раслау хакында»гы карарына үзгәреш кертү турында**

2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы законының 6 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2025 елның 7 апрелендәге под-608/25 номерлы «2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы “Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү өчен тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турында” әмергә үзгәрешләр кертү хакында»гы әмеренә таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 940 номерлы карары (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 21 июлендәге 2335 номерлы, 2024 елның 4 октябрендәге 4198 номерлы, 2024 елның 25 декабрендәге 5345 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе составындагы муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләренең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә), 2.1. пунктны түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«2.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе структурасына керә торган мәгълүмати-методик бүлекләр хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Айга төп оклад күләме, сум** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Төп гомуми белем, урта гомуми белем** | **Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем** | **Аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификация-ләре бирү белән раслана торган югары һөнәри белем** |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 22271,0 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 22276,0 |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләренең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати- | - | - | 22362,0 |

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Айга төп оклад күләме, сум** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Төп гомуми белем, урта гомуми белем** | **Квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләре әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем** | **Аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификацияләре бирү белән раслана торган югары һөнәри белем** |
| | техник яктан тәэмин итү буенча үзенә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бүлек мөдире (башлыгы) урынбасары | | | |
| | Структур бүлекчә: муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге педагогик хезмәткәрләренең һөнәри-квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү буенча үзенә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган бүлек мөдире (башлыгы) | - | - | 22446,0» |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**